**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 гыйнварындагы 13 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 5 декабрендәге 5035 номерлы**
**«Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында “Кунакчыллык йолдызлары – 2024” III төбәкара һөнәри осталык фестивален уздыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары – 2024» III төбәкара һөнәри осталык фестивале турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү зарурлыгы белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 5 декабрендәге 5035 номерлы «Туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында “Кунакчыллык йолдызлары – 2024” III төбәкара һөнәри осталык фестивален уздыру турында»гы карарының 1 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.2 пунктта «2025 елның 28 гыйнвары» сүзләрен «2025 елның 12 феврале» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 5.3 һәм 7.9 пунктларда «2025 елның 5 февраленнән 21 февраленә кадәр» сүзләрен «2025 елның 24 февраленнән 3 мартына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 6.5 пунктта «2025 елның 10 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2025 елның 27 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 6.6 пунктта «2025 елның 13 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2025 елның 30 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 6.8 һәм 6.9 пунктларда «2025 елның 20 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2025 елның 10 февраленә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 6.12 пунктта «2025 елның 22 гыйнварыннан 27 гыйнварына кадәрге» сүзләрен «2025 елның 10 февраленнән 12 февраленә кадәрге» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 6.14 пунктта «2025 елның 28 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 12 февраленнән» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 7.8 пунктта «2025 елның 30 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2025 елның 17 февраленә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.9. 8.10 һәм 9.5 пунктларда «2025 елның 28 феврале» сүзләрен, тиешле килешләргә куеп, «2025 елның 3 марты» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 9.6 пунктта «2025 елның 21 февраленнән» сүзләрен «2025 елның 3 мартыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**